| | | |
|---|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2026 п.г.т. Алексеевское № 49

**«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 21.07.2022 ел,№ 126 карары белән расланган «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында Нигезләмәнең 6,9, 15, 16 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 21.07.2022ел, № 126 карары белән расланган «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында Нигезләмәнең 8 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган мәгълүмат җирле үзидарә органының (муниципаль органның) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) тапшырыла.».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**